**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 март № 125

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 13 декабрь, 980 нче, 2014 ел, 25 декабрь, 1027 нче, 2015 ел, 24 декабрь, 967 нче, 2015 ел, 30 декабрь, 1021 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның 2 бүлегендә «Дәүләт һәм бүтән ярдәм чаралары» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм «Газпром газ-мотор ягулыгы» ҖЧҖ арасындагы Газ-мотор ягулыгы базарын үстерүнең кайбер стимуллаштыручы программаларын тормышка ашыру турында килешү кысаларында 2016 елда Татарстан Республикасында юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең һәм физик затларның транспорт чараларын газ-мотор ягулыгы сыйфатында компримирлаштырылган табигый газны кулланугa күчерүне стимуллаштыру буенча чараларны тормышка ашыру планлаштырыла.»;

Программаның 2 бүлегендә 16 нчы таблицаның «Транспорт чарасы исеме» баганасындагы юлны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Физик затларның, юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең автотранспорт чаралары»;

Программага кушымтада:

4 нче таблицаның 24 юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. Республикада эксплуатацияләнүче автотранспорт чараларын ГМЯ куллануга яңадан җиһазлау | ТР Икътисад министрлыгы, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе, Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары | Автотранспорт чараларын ГМЯ куллануга яңадан җиһазлау, бирәмлек | 1 500 | 375 000 | 0 | 75 000 | 300 000». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\125.docx